ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» февраля 2025ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр тибындагы поселогында «Ясалма сулык һәм җиләк-җимеш культураларын сугару системасын төзү «территориясен планлаштыруны карау буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында.**

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар һәм иҗтимагый фикер алышулар турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башлыгы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр тибындагы поселогында «ясалма сулык һәм җиләк-җимеш культураларын сугару системасын төзү «темасына гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

- Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов;
- Татарстан Республикасы Балтач районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы И.Н. Сәгъдиев;
- Татарстан Республикасы Балтач районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары Р. И. Фазылянов;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И. М. Фәтхетдинов;
- Татарстан Республикасы Балтач районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы Р. С. Фатыйхов;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе И. Д. Габдрахманов;

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлауларны уздыру срогы кызыксынган затларга аларны уздыру турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр бер айдан артмаска тиешлеген билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru).

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин